**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об охране труда в Республике Татарстан» и признании утратившими силу отдельных положений законодательных актов Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
18 февраля 2021 года

## Статья 1

Внести в Закон Республики Татарстан от 10 декабря 1997 года № 1417 «Об охране труда в Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 6 августа 2003 года № 30-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1997, № 12; 2003, № 8; 2005, № 10 (I часть); 2009, № 2, № 7 – 8 (I часть), № 12 (I часть); 2011, № 3; 2012, № 5 (I часть); 2014, № 6 (II часть), № 7) следующие изменения:

1) статью 2 изложить в следующей редакции:
«Статья 2. **Сфера действия настоящего Закона**

Действие настоящего Закона распространяется на работодателей, осуществляющих свою деятельность на территории Республики Татарстан, работников, состоящих с работодателями в трудовых отношениях, а также иных лиц в случаях, предусмотренных законодательством Российской Федерации и Республики Татарстан.»;

2) в части второй статьи 3 слова «, указанными в статье 2 настоящего Закона,» исключить;

3) в статье 6:
а) в абзаце четвертом слова «о профессиональной пригодности по результатам» заменить словами «о результатах»;

б) абзац десятый изложить в следующей редакции:

«обращение в соответствующие органы государственной инспекции труда при отказе работодателя в составлении акта о несчастном случае на производстве или при несогласии пострадавшего с изложенными в акте обстоятельствами и причинами несчастного случая. Решения органов государственной инспекции труда могут быть обжалованы в суд;»;

в) абзац тринадцатый признать утратившим силу;

г) абзац четырнадцатый изложить в следующей редакции:

«возмещение вреда, причиненного ему в связи с исполнением трудовых обязанностей, и компенсацию морального вреда в порядке, установленном Трудовым кодексом Российской Федерации, иными федеральными законами;»;

4) часть десятую статьи 7 признать утратившей силу;

5) статью 8 признать утратившей силу;

6) части первую и третью статьи 9 признать утратившими силу;

7) абзац второй статьи 10 после слов «определяют основные направления деятельности» дополнить словами «в области охраны труда»;

8) в статье 12:

а) второе предложение части третьей дополнить словами «, за исключением организаций, проводящих специальную оценку условий труда, порядок аккредитации которых устанавливается законодательством о специальной оценке условий труда»;

б) часть пятую признать утратившей силу;

9) часть третью статьи 18 признать утратившей силу;

10) статью 25 изложить в следующей редакции:

«Статья 25. **Ответственность за нарушение требований охраны труда**

Лица, виновные в нарушении требований охраны труда, несут ответственность в соответствии с федеральным законодательством.»;

11) статьи 26 – 28 признать утратившими силу.

**Статья 2**

Признать утратившими силу:

1) пункты 12 – 14 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 11 октября 2005 года № 101-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан

«Об охране труда в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2005, № 10 (I часть);

2) пункт 9 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 3 февраля 2009 года № 9-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об охране труда в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 2);

3) подпункт «б» пункта 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 17 мая 2012 года № 25-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об охране труда в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012, № 5 (I часть);

4) пункт 4 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 23 июля 2014 года № 60-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об охране труда в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 7);

5) подпункт «б» пункта 1, пункт 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 24 июля 2014 года № 76-ЗРТ «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 7; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 4).

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
05 марта 2021 года
№ 9-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2003 елның 6 августындагы 30-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 12; 2003, № 8; 2005, № 10 (I өлеш); 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 5 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2 статья. **Әлеге Законның гамәлдә булу даирәсе**

Әлеге Законның гамәлдә булуы Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы эш бирүчеләргә, эш бирүчеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы хезмәткәрләргә, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда башка затларга кагыла.»;

2) 3 статьяның икенче өлешендә «Әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән юридик» сүзләрен «Юридик» сүзенә алмаштырырга;

3) 6 статьяда:
а) дүртенче абзацта «нәтиҗәләре буенча һөнәри яраклылыгы хакында» сүзләрен «нәтиҗәләре турында» сүзләренә алмаштырырга;
б) унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«эш бирүче бәхетсезлек очрагы турында акт төзүдән баш тартса яисә зыян күрүче актта бәян ителгән бәхетсезлек очрагы һәм аның сәбәпләре белән килешмәсә,

дәүләт хезмәт инспекциясенең тиешле органнарына мөрәҗәгать итәргә. Дәүләт хезмәт инспекциясе органнары карарларына судка шикаять бирелергә мөмкин;»;

в) унөченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексында, башка федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә аңа хезмәт вазыйфаларын башкаруга бәйле китерелгән зыянның каплануына һәм әхлакый зыянның компенсацияләнүенә;»;

4) 7 статьяның унынчы өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

5) 8 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

6) 9 статьяның беренче һәм өченче өлешләрен үз көчләрен югалткан дип танырга;

7) 10 статьяның икенче абзацында «оешмаларда» сүзеннән соң «хезмәтне саклау өлкәсендәге» сүзләрен өстәргә;

8) 12 статьяда:

а) өченче өлешнең икенче җөмләсенә «оешмалар» сүзеннән соң «, аккредитацияләнүе тәртибе хезмәт шартларын махсус бәяләү турында законнар белән билгеләнә торган хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүче оешмалардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

б) бишенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

9) 18 статьяның өченче өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

10) 25 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25 статья. **Хезмәтне саклау таләпләрен бозган өчен җаваплылык**

Хезмәтне саклау таләпләрен бозуда гаепле затлар федераль законнар нигезендә җаваплылыкка ия булалар.»;

11) 26 – 28 статьяларны үз көчләрен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 11 октябрендәге 101-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 12 – 14 пунктларын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 10 (I өлеш);

2) «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 3 февралендәге

9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 9 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2);

3) «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 17 маендагы 25-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 пунктының «б» пунктчасын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 5 (I өлеш);

4) «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 4 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 7);

5) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктының «б» пунктчасын, 2 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 4).

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 05 март
№ 9-ТРЗ